**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2023-2024 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 47 балл**

## I. Теоретик тестлар (10 балл).

1. Кешенең тышкы кыяфәтен, йөз төзелешен, буй-сынын һәм үз-үзен тотышын тасвирлау (1 балл):

1) әдәби деталь
2) **портрет**
3) хронотоп

2. Әдәбиятның хис-кичерешләрне белдерүгә, чагылдыруга корылган, аеруча осталык һәм махсус чаралар таләп итә торган төре (1 балл):

1) шигырь
2) поэма
3) **лирика**

3. Лиро-эпик әсәрләр генә күрсәтелгән рәтне сайлап алыгыз (1 балл):

1) **«Идегәй», «Мокамай»**
2) «Мокамай», «Милли моңнар»
3) «Милли моңнар», «Идегәй»

4. Күрсәтелгән образлар арасыннан кайсы әсәрдә символ вазифасын үти (1 балл):

1) «Идегәй» әсәрендә акбүз ат
**2) Г.Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәрендә кызыл чәчәкләр**
3) Н.Думавиның «Яшь ана» әсәрендә чәчәкләр

5. Табигый, җанлы сөйләм һәм телнең үзендә булган образлы сурәтләү чаралары ярдәмендә тормышны бөтен нечкәлекләре белән вакыйгалар дулкынында укучыга җиткерә (1 балл):

1) **чәчмә әсәрләр**
2) тезмә әсәрләр
3) лирик әсәрләр

6. Чәчмә әсәрләр генә булган рәтне билгеләгез (1 балл):

1) «Идегәй», «Яшь ана», «Кызыл чәчәкләр»
2) **«Кызыл чәчәкләр», «Яшь ана», «Акчарлаклар»**
3) «Кызыл чәчәкләр», «Яшь ана», «Җан Баевич»

7. Билгеләмәне игътибар белән укыгыз һәм аңа туры килгән төшенчәне язып куегыз: «*Әсәрдә персонажның эчке дөньясын, ягъни фикерләрен, хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын матур әдәбиятка хас чаралар аша тулы итеп, җентекләп сурәтләү осталыгы*» (2 балл):

Җавап: **психологизм**

8. Жанрларны лириклыктан эпиклыкка күчә бару тәртибендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны гына үсә бару тәртибендә языгыз (2 балл):

1) поэма
2) күңел лирикасы
3) повесть

Җавап: **213**

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## II. Әдип иҗатына кагылышлы биремнәр (26 балл).

1. Шагыйрь буларак, ул үзенең вазифасын милләткә хезмәт итүдә таба. Нинди генә темага язмасын, һәрвакыт көчсезләр, рәнҗетелгәннәрне яклый. Оялчан булса да, иҗатында кыю сүзле була. Рухи байлыкны бөтен нәрсәдән өстен күрә. Аның әсәрләрендә гади халык күңелендә яшәгән уй-кичерешләр, моң-сагыш, милли азатлык турындагы өметләр гәүдәләнеш таба. Кем турында сүз бара? (2 балл):

Җавап: **Габдулла Тукай**

2. Г.Тукайның әсәрләре генә урын алган рәтне билгеләгез (1 балл):

1) **«Милли моңнар», «Туган тел», «Җәйге таң хатирәсе»**
2) «Милләтә», «Җәйге таң хатирәсе», «Мокамай»
3) «Җәйге таң хатирәсе», «Туган тел», «Халкыма»

3. Г.Тукайның «Милләтә» шигыреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? Дөрес җавапны билгеләгез (2 балл):

*Үзем үлсәм дә, гаҗиз исемем үлмәсен, югалмасын;*
*Минем тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен.*

*Әгәр милләт мине илтифат итеп искә алса, -*
*Шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем.*

1) Шагыйрьнең төп максаты һәм бәхете – үзен илтифат белән искә алулары
2) Шагыйрьнең тырышлыгы һәм эшләре бушка китмәскә тиеш

3) **Шагыйрь үзе исән булганда милләтенә хезмәт итәргә, үз артыннан милләткә файдалы эшләр кылып калдырырга тиеш, шагыйрь кешенең төп максаты һәм бәхете шул**

4. Г.Тукайның беренче әсәрләре кайда иҗат ителә башлый? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) **Җаек**
2) Кырлай
3) Казан

5. Г.Тукай укыган мәдрәсә. Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) «Галия»
2) «Мөхәммәдия»
3) **«Мотыйгия»**

6. Г.Тукай кайсы елда Казанга кайта? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) 1886
2) **1907**
3) 1913

7. Г.Тукай әдәбиятның кайсы төрендә актив эшли? (2 балл):

Җавап: <u>**поэзия / шигърият / лирика**</u>

8. Г.Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигыре кайсы жанрга карый? (2 балл):

1) күңел лирикасы
2) **пейзаж лирикасы**
3) лирика

9. Г.Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигыреннән алынган әлеге өзектә кулланылган 2 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз (4 балл):

*Шат үләнлекләр, тәбәссемдә чәчәкләр, ләләләр;*
*Сандугачлардан ява, яңгыр кеби, мәдхияләр.*

*Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене*
*Күктә аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме.*

Җавап: <u>**чагыштыру, инверсия, эпитет, метафора**</u>

10. Г.Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигырендә лирик геройга бәя (характеристика) бирегез (5 балл):

*Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;*
*Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.*

*Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә;*
*Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә.*

*Пәрдәдән чыкты, ачылды ямь-яшел кыр һәм япан;*
*Китте инде кап-кара каплап ята торган чапан.*

*Тын гына яткан,ялыккан, төн буенча көн көтеп,*
*Ялтырап, җәйлеп ята күлләр, сихерле күзге күк.*

*Шат үләнлекләр, тәбәссемдә чәчәкләр, ләләләр;*
*Сандугачлардан ява, яңгыр кеби, мәдхияләр.*

*Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене*
*Күктә аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме.*

*Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак җәйге таң;*
*Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң.*

11. Автор нинди идея (фикер) җиткерә? Ул шигырьнең кайсы юлларына салынган? (5 балл)

**Җәйге таң күренеше илаһи матурлыкка ия, ул шагыйрь күңеленә илһам бирә, илһам уята һ.б.**

**III. Иҗади бирем (10 балл).**

«Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә, / Мөгаллимне олуг күрсә, белергә кушканын белсә...» юлларына нигезләнеп, 10 җөмләдән ким булмаган күләмдәге инша языгыз.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2023-2024 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 48 балл**

## I. Теоретик тестлар (10 балл).

1. Читләтеп әйтүнең бер формасы, күренеш-хәлләрне, сыйфатларны предмет-сурәтләр атау (1 балл):
1) метафора
2) **аллегория**
3) символ

2. Җөмләдә сүзләрнең грамматик тәртибен үзгәртү, мәгънә басымы төшә торган сүзне алга күчереп кую (1 балл):
1) синтаксик фигура
2) **инверсия**
3) метафора

3. Лирик әсәрләр генә күрсәтелгән рәтне сайлап алыгыз (1 балл):
1) «Идегәй», «Ана догасы»
2) «Алсу», «Таһир-Зөһрә»
3) **«Тәәссер», «Нәсыйхәт»**

4. Күрсәтелгән образлар арасыннан кайсы әсәрдә символ вазифасын үти (1 балл):
1) М.Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә «Н» авылы
2) **Ш.Камалның «Буранда» әсәрендә буран**
3) Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәрендә хат

5. Әдәбиятның кешене хәрәкәттә, каршылыкларда күрсәтүгә, тормышның бер кечкенә өзеге аша кеше характерларын ачуга корылган төре (1 балл):
1) **драматургия**
2) проза
3) драма

6. Чәчмә әсәрләр генә булган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) «Бер хәрабәдә», «Йөзек кашы», «Яз»
2) «Әйтелмәгән васыять», «Буранда», «Сүнгән йолдызлар»
3) **«Йөзек кашы», «Буранда», «Искәндәр»**

7. Билгеләмәне игътибар белән укыгыз һәм аңа туры килгән төшенчәне язып куегыз: «*Әсәрнең эмоциональ көйләнеше. Язучының фикерен җиткерү өчен сайланган хис яңгырашы. Ул әсәрнең идеясе, жанры белән дә бәйләнештә була. Героик, романтик, трагик, сатирик һ.б. төрләре бар*» (2 балл):

Җавап: **пафос**

8. Жанрларны лириклыктан эпиклыкка күчә бару тәртибендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны гына үсә бару тәртибендә языгыз (2 балл):

1) дастан
2) гражданлык лирикасы
3) хикәя

Җавап: **213**

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## II. Әдип иҗатына кагылышлы биремнәр (28 балл).

1. 1886 елның 1 гыйнварында Казанның Яңа бистәсендә туа. Мәдрәсәдә белем ала, мәдрәсә каршындагы рус классын уңышлы тәмамлый. Университетка керү хыялы белән яна. 1907 елда паралич сугып, гомерлеккә аяксыз кала. Кем турында сүз бара? (2 балл):

Җавап: **Фатих Әмирхан**

2. Ф.Әмирханның әсәрләре генә урын алган рәтне билгеләгез (1 балл):

1) **«Хәят», «Бер хәрабәдә»**
2) «Бер хәрабәдә», «Буранда»
3) «Бер хәрабәдә», «Искәндәр»

3. Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә» әсәреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? Дөрес җавапны билгеләгез (2 балл):

*...Өрәк, Әсманың өрәге! Юк, бу сүз ялган! Бөтен дөнья халкы килеп, үз күзләре белән күргәнлекләрен сөйләсәләр дә, мин моңа ышанмыйм! И мәлгунь халык, ялганламагыз! Әсма өрәге – ул ни дигән сүз? Фәрештәләрдән өрәк чыгамы соң? Шул минем белән менә бу эскәмиядә утырып торган, бөдрә сары чәчле, зәңгәр күзле, фәрештә шикелле Әсмадан? Юк-юк, мин йөрәк яргыч итеп кычкырам, юк!..*

- *Ләгънәт сиңа, и тормыш! Әүвәл алдыйсың, аннан соң мыскыллыйсың!*

1) Фәрештәдән өрәк чыга алмый

2) Тормыш кешене алдауга, аннан соң мыскыллауга корылган

3) **Тормышның мәгънәсе юк, Матурлык, Яшьлек, Мәхәббәт, Бәхет барысы да вакытлы**

4. Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә» әсәрендә Хикәяләүче, хәрабә һәм Фәхрия образларын төркемнәргә бүлеп языгыз (1 балл):

1) төп герой **Хикәяләүче**

2) символик образ **хәрабә**

3) эпизодик герой **Фәхрия**

5. Ф.Әмирхан укыган мәдрәсә. Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) «Галия»

2) **«Мөхәммәдия»**

3) «Мотыйгия»

6. Ф.Әмирханның беренче әсәре кайсы елда дөнья күрә? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) 1886

2) **1907**

3) 1926

7. Ф.Әмирхан әдәбиятның кайсы төрендә актив эшли? (2 балл):

Җавап: **<u>проза / эпик төр</u>**

8. Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә» әсәре кайсы жанрга карый? (2 балл):

Җавап: **<u>хикәя</u>**

9. Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә» әсәреннән алынган әлеге өзектә кулланылган 2 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз (4 балл):

*...Аннан соң игътибарсыз гына, карамый гына, мине узып китте дә үзенең җеннәренә сөйләп барган сымак кыяфәт һәм әллә нинди төссез тавыш белән: - Күптән өйнең ул ягында кеше тормый. Анда бичура ияләнгән, - диде.*

*Бу сүз минем йөрәгемне туңдырып җибәрде.*

- *Мин белгән заманнарда анда фәрештәләр торалар иде.*

*Карчык мине әллә нинди сукмаклардан әйләндерде дә ярым җимерелгән бер ишек һәм паркетлары кырылган шакшы бер коридор аркылы биек түшәмле, зур-зур тәрәзәле бер бүлмәгә алып керде.*

Җавап: **<u>чагыштыру, метафора, эпитет, каршы кую һ.б.</u>**

10. Әлеге өзектә хикәяләүченең кичерешләрен ачу барышында Ф.Әмирхан нинди образлардан һәм алымнардан файдалана? (6 балл):

*...Әйе, кайчандыр бу агачта сандугачлар сайрый иде!*

*Бу хатирәләр минем күз алдымнан кадерле төшләр шикелле булып үтеп киттеләр. Бу эшләрнең булып-булмаганлыгын, бу эшләрне мин төшемдә генә күргәнме, әллә болар кайчандыр бервакыт өнемдә булып үткәннәрме икәнен аңлый алмый бераз утыргач, мин, ватык эскәмиядән торып, бакчаның урта бер җирендәге беседканы эзләргә керештем.*

*Кайчандыр бакчадагы хәятның мәркәзе булып торган бу беседка бу көн инде эченә керә алмаслык булып җимерелгән, кычытканнар белән чолганып утыра иде. Мин, аңа барып җитмәстән тукталып, пошынып, аның ишегенә карап тордым. Әгәр ул ишекнең теле булып та, кайчандыр үзе аркылы йөргән кешеләрнең, кайчандыр үзе аркылы аккан тормышның моңлы тарихын сөйләсә иде, мин, шөбһәсез, җиргә егылып елар идем.*

*Әле дә хәтеремдә: моннан биш ел элек бер кичне аның эчендә Фәхрия гитара уйнап утырган иде. Әсма белән без икәү, аңа күренми генә бер читтә торып, аның уйнаганын тыңлаган идек. Гитара Фәхриянең кулында елый, алтын тавышлы фәрештә елаган шикелле, моң һәм хәят катыш тавыш белән елый, һәм аның елашына Фәхриянең коңгырт күзләре, моңланып, хәяттан арыган шикелле хәлсезләнеп җавап бирәләр иде. Кем белә, бәлки, ул вакытта ук ул гитара һәм ул күз алдындагы бүгенге көнне күреп, бүгенге хәятсызлык, хәрабәлекне сизенеп моңланганнардыр. Ләкин Әсма белән мин, аны сизмичә, кичнең караңгысына кәефле чолганып, күз алдыбыздагы бу якты беседканы сөеп, күңелләребез белән иркәләп карап торган идек...*

**Сандугач, бакча, ишек теле, гитара елавы, алтын тавышлы фәрештә, хәрабә һ.б. образлар, үткәнне һәм хәзергене каршы кую, психологизм, төсләр һәм тавышлар һ.б. алымнар кулланыла.**

11. Әлеге өзектә бакчаның үткәнен һәм хәзергесен янәшә куеп, язучы нинди фикерләр җиткерә? (6 балл)

**Тормыш-яшәештәге бөтен әйбернең – Матурлыкның да, Яшьлекнең дә, Мәхәббәтнең дә, Бәхетнең дә вакытлы булуы, үтеп китүе, үз артыннан үкенеч һәм сызлану гына калдыруы турында сөйли. Тормышның мәгънәсе юк дип кабатлый.**

## III. Иҗади бирем (10 балл).

«Яманга юлдаш булсаң – бәла тагар, / Еланга ярдәм итсәң – кулың чагар» юлларына нигезләнеп, 10 җөмләдән ким булмаган күләмдәге инша языгыз.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2023-2024 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 50 балл**

## I. Теоретик тестлар (10 балл).

1. Эпик, драма, лиро-эпик әсәрләрдә вакыйга-хәлләр яки кеше холкы-характерының үсү-үзгәрү тарихы (1 балл):

1) вакыйгалылык
2) **сюжет**
3) сюжет элементлары

2. Мәгънә ягыннан капма-каршы булган төшенчә яисә образларны белдерүче стилистик фигура (1 балл):

1) **антитеза**
2) антоним
3) эпитет

3. Лирик әсәрләр генә күрсәтелгән рәтне сайлап алыгыз (1 балл):

1) «Җырларым», «Хикмәтләр», «Нуры содур»
2) «Ышанма», «Сагыну», «Төхфәи мәрдан»
3) **«Җырларым», «Хикмәтләр», «Ышанма»**

4. Күрсәтелгән образлар арасыннан кайсы әсәрдә символ вазифасын үти (1 балл):

1) Ф.Әмирханның «Хәят» әсәрендә бакча
2) **М.Җәлилнең «Кошчык» шигырендә кош**
3) Г.Кутуйның «Сагыну» әсәрендә туган ил

5. Әдәбиятның кешене башка кешеләр һәм вакыйгалар уртасында тасвирлауга корылган төре (1 балл):

1) драматургия
2) **проза**
3) повесть

6. Лиро-эпик әсәрләр генә булган рәтне билгеләгез (1 балл):

1) **«Төхфәи мәрдан», «Хөсрәү вә Ширин», «Сагыну»**
2) «Нуры содур», «Хөсрәү вә Ширин», «Җырларым»
3) «Төхфәи мәрдан», «Кыйссаи Йосыф», «Хәят»

7. Билгеләмәне игътибар белән укыгыз һәм аңа туры килгән төшенчәне язып куегыз: «*Билгеле бер идеал яктылыгында тормышны үзгәртеп тасвирлауга нигезләнгән иҗат юнәлеше, тибы*» (2 балл):

Җавап: **романтизм**

8. Жанрларны лириклыктан эпиклыкка күчә бару тәртибендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны гына үсә бару тәртибендә языгыз (2 балл):

1) нәсер
2) пейзаж лирикасы
3) повесть

Җавап: **213**

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**II. Әдип иҗатына кагылышлы биремнәр (30 балл).**

1. Гомерен милләткә багышлаган шәхесләрнең берсе. Ул җирдә яшәвенең максатын татар әдәбиятын яңа баскычка күтәрүдә таба, милләтен алдынгы һәм бәхетле итеп күрергә тели. Аның зәвыклы, дөньяны-яшәешне күреп кенә түгел, тоеп һәм сиземләп аңлатучы бай күңеле, язмыш сынауларына бирешмәгән көчле рухы, әдәбиятта яңа сукмаклар салган проза әсәрләре бүгенге укучыны да үзенә җәлеп итә. Кем турында сүз бара? (2 балл):

Җавап:_ **Фатих Әмирхан**

2. Ф.Әмирхан кайсы өлкәләрдә эшли (1 балл):

1) проза, драматургия, поэзия, журналистика
2) проза, драматургия, әдәби тәнкыйть, поэзия
3) **проза, драматургия, әдәби тәнкыйть, журналистика**

3. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? Дөрес җавапны билгеләгез (2 балл):

...*Салихның да кулында, теге егетнеке шикелле, бер думбрасы бар икән. Ул, шул думбрага бик матур чиертеп, кычкырып җырлап, Хәят утырган тәрәзәгә таба килә икән...*

*Салихның «Сөям сине» дигән, сүзсез җырлана торган җыры бөтен бакчаны яңгыратса да, Хәяттан башкаларга: Борһан абзый, Газизә абыстай һәм Бибигә ишетелми икән, ләкин Хәятка аермачык ишетелә икән....*

*Боларны хыялына китергәч, Хәят чынлап та кытыкланып китте, кызарынды һәм, үз-үзеннән оялып, мендәренә барып капланды да:*

*– Илаһи, мәхәббәт бир! Илаһи, гомерлек мәхәббәт бир инде! – диенде.».*

1) Мәхәббәт хыял белән бергә яши
2) **Кешенең үзе яраткан кешесе белән тормыш корырга, бәхетле булырга хакы бар, ләкин татар тормышы чикләнгән**
3) Мәхәббәт – илаһи көч

4. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәреннән алынган әлеге өзекләр нинди теоретик төшенчәгә туры килә (2 балл):

*«Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсу-ак йөзенә, могҗизалы якутлар шикелле, нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде»; «Ул озын, куе вә үз-үзләреннән күперенеп тора торган, кара ефәк көлтәсе шикелле чәчләрен тараганда ...; Хәят әле бары уналтынчыда гына булса да, быел кыш ул, кинәт үсеп китеп, буе-сыны белән инде «җиткән» кызлардан аермасыз булган иде... Аның быел тектергән ал ефәк декольте күлмәге инде җиткән кызлар кия торган модаларның иң соңгысы белән тегелгән иде».*

Җавап: **<u>портрет</u>**

5. Ф.Әмирхан иҗат дәвамында кайсы газета-журналлар белән эш итә (1 балл):
1) **«Кояш», «Аң»**
2) «Кояш», «Казан утлары»
3) «Ватаным Татарстан», «Ялт-Йолт»

6. Ф.Әмирхан әдәбиятның кайсы чорында актив иҗат эше белән шөгыльләнә? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):
1) XIX гасыр ахыры
2) **XX йөз башы**
3) 1920 еллар

7. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәре әдәбиятның кайсы төренә һәм жанрына карый? (2 балл):

Җавап: **<u>проза / эпик төр, повесть</u>**

8. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәреннән алынган әлеге өзектә кулланылган 2 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз (4 балл):

... *Михаил да, Лиза шикелле үк, Хәятның кечкенәдән бергә уйнап үскән иптәше иде. Ул, үткән көз Казан университетына кабул ителгәнлектән, бу кышны Казанда уздырып, кичә генә N шәһәренә кайткан иде.*

*Алар өчәүләшеп яр өстеннән Иделгә карап тора торган эскәмиягә килеп утырдылар. Иделнең киңлеге, иркенлеге һәм көчле агышы, аның өстендәге пароходчыклар һәм ал арга тагылган баржалар, төрле җирләргә таралган, бер яктан икенче якка чыгарга азаплана торган көймәләр, икенче якта күренеп тора торган авыл һәм аның кыры һәм көтүе иркен һәм матур күренәләр иде...*

*Әнә бер кеше йөртә торган (пассажирский) пароход, аның көпчәк тавышы Идел өстен яңгырата, морҗасыннан чыккан кара төтене, артында калып, һәм һаваларга күтәрелә, һәм дулкыннарга кадәр төшә, ләкин шул ничә йөз кеше төягән пароход моннан бик кечкенә күренә, өстендәге кешеләре чыпчыклар кадәр генә... Кояш, шул биек кояшның күз чагылдыргыч шәүләсе, пароходчык калдырган дулкынчыкларда сикеренеп, чумып, шаярып йөри..*

Җавап: **<u>чагыштыру, эпитет, антитеза, метафора, сынландыру һ.б.</u>**

9. Әлеге өзектә Хәятнең кичерешләрен ачу барышында Ф.Әмирхан нинди образлардан файдалана? (3 балл):

*...Төн килде. Бөтен табигать, бөтен җир йөзе, бөтен яшь йөрәкләр шикелле Хәят та язгы төннәрне сөя иде. Язның салкынчарак, хуш исле төннәре, бигрәк тә ул төннәрнең шундый хуш исле булучылыгы Хәятның йөрәгендә үзенә белемсез бер тойгы уята иде. Бу тойгыда җиңелчә генә моң, җиңелчә генә шатлык, нәрсәнедер җиңелчә генә сагыну, нәрсәнедер җиңелчә генә көтү, нәрсәгәдер җиңелчә генә куану, тагы әллә нәтэсәләр бар иделәр. Хәят язгы төннәрдә бу тойгы белән исерә дә, үз-үзен онытып, томанлы рәхәтлек эченә батып кала иде.*

*Бүген төн Хәятка, үзенең салкынчарак кына аязлыгы, язлыклы хуш исе эченә төрендереп, катгый бер карар да китерде.*

*Хәят, һәр көнге гадәтенчә, бакчага ачылган тәрәзәсе төбенә килеп утырды да, бакчадан керә торган салкынча һаваны зур-зур йотымнар белән эчеп, әлеге үзенә билгесез тойгының томанлы рәхәтлегенә талды. Һәм, шул томанлы рәхәтлек эченә төренеп, иртәдән бирле башын әйләндергән мәсьәләне салмак һәм тыныч кына чишеп ташлады.*

*Карар булды: Хәят Салихка барырга риза! Салихка баргач, бу соңгы айларда була башлаган эч пошу бәласе дә бөтенләй бетәчәк булды. Чөнки Хәят тормышының тойгы белән генә беленә торган китек ягын Салих бөтенләй тутырачак...*

**Төн, язгы табигать, томан, бакча һ.б.**

10. Әлеге өзектә Хәятнең кичерешләрен сурәтләп, язучы нинди фикерләр җиткерә, нинди проблемалар күтәрә? (6 балл)

**Ф.Әмирхан татар тормышының чикләнгән булуын күрсәтә, Хәят үз күңеленә каршы килеп, әти-әнисе теләгән кеше белән тормыш корырга карар кыла, хатын-кыз азатлыгы проблемасы күтәрелә. Ләкин**

**мондый мәхәббәт кеше тормышына бәхет китерми, төн, язгы салкынча табигать образлары, метафора буларак, укучыны шушы фикергә китерә һ.б.**

11. Фатих Әмирхан иҗатына хас 3 сыйфатны, үзенчәлекне атагыз (6 балл):

1) үз иҗатында нинди геройларга зур урын бирә? **Бәхет, яшәү мәгънәсен эзләгән, шәхси тормышында бәхет таба алмаган геройларга зур урын бирә һ.б.**

2) нинди проблемалар күтәрә? **Хатын-кыз азатлыгы, татар тормышының чикләнгән булуы, яшәештә һәрнәрсәнең вакытлы булуы һ.б.**

3) нинди алымнарга еш мөрәҗәгать итә? **Импрессионистик алымнарга, каршы кую алымына, психологизмга, тавыш һәм төсләргә еш мөрәҗәгать итә һ.б.**

**III. Иҗади бирем (10 балл).**

«Акыллы ир «олугъ мин» дип лаф ормас / Аның затында алдау, хыянәт булмас...» юлларына нигезләнеп, 15 җөмләдән ким булмаган күләмдәге инша языгыз.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2023-2024 уку елы) 10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 52 балл**

**I. Теоретик тестлар (10 балл).**

1. Сүз сәнгатенә хас сыйфатларны, билгеләрне өйрәнә торган фән (1 балл):
1) әдәби барыш (процесс)
2) әдәбият тарихы
3) **әдәбият теориясе**

2. Гадәттән тыш кызык, мавыктыргыч, гыйбрәтле вакыйгалар турында бәян итүче эпик (кайчак лиро-эпик) жанр (1 балл):
1) мәдхия
2) **кыйсса**
3) газәл

3. Урта гасыр әдәби ядкярләре генә күрсәтелгән рәтне сайлап алыгыз (1 балл):
1) **«Кыйссаи Йосыф», «Хөсрәү вә Ширин», «Сөһәйл вә Гөлдерсен»**
2) «Кыйссаи Йосыф», «Хөсрәү вә Ширин», «Хисаметдин менла»
3) «Кыйссаи Йосыф», «Сөһәйл вә Гөлдерсен», «Хәят»

4. Күрсәтелгән образлар арасыннан кайсы әсәрдә символ вазифасын үти (1 балл):
1) **Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә төш**
2) Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә Хөсрәү
3) С.Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрендә Гөлдерсен

5. Әдәби әсәрдә чагылдырылган вакыт һәм урын бөтенлеге (1 балл):
1) реминисценция
2) **хронотоп**
3) традиция

6. Гарәп язулы истәлекләр генә булган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) **«Диване лөгатет-төрк», «Котадгу белек», «Һибәтел-хәкаик»**
2) «Диване лөгатет-төрк», «Һибәтел-хәкаик», «Күлтәгин истәлеге»
3) «Һибәтел-хәкаик», «Кыйссаи Йосыф», «Билгә каган истәлеге»

7. Билгеләмәне игътибар белән укыгыз һәм аңа туры килгән төшенчәне язып куегыз: «*Нигезендә яңача язу, яңа әдәби алымнар яткан, тормышны*

*тәртипсез хәлдә – хаос хәлендә сурәтли торган, күп катламлы тормыш моделе тудырылган иҗат тибы*» (2 балл):

Җавап: **модернизм**

8. Образларны сәнгати яктан катлаулана бару тәртибендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны гына үсә бару тәртибендә языгыз (2 балл):

1) деталь
2) символ
3) метафора

Җавап: **132**

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

**II. Әдип иҗатына кагылышлы биремнәр (32 балл).**

1. «Мин китапның әһәмиятен аңларлык яшькә җиткәндә, халык арасында төрле исемдә байтак кына әсәр укыла иде. Ләкин шулардан мин халыкның рухи хәзинәсен бу китап кадәр баеткан, халык күңеленә шулкадәр көчле тәэсир иткән башка бер китапны белмим. Бу әсәрне йөз еллар буенча безнең борынгы бабаларыбыз укып килгән, безнең әти-әниләребез, апа-абыйларыбыз укып үскән. Мин малай чакта, безнең авылда бу кыйсса иң затлы, иң кыйммәтле китаплардан санала, кияүгә чыкканда, аны кызларга иң кадерле истәлек сыйфатында бүләк итеп бирәләр иде…» Г.Бәширов истәлекләреннән алынган әлеге юлларда кемнең кайсы әсәре турында сүз бара? (2 балл):

Җавап: **Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре**

2. Кол Гали иҗаты әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) Казан ханлыгы чоры
2) **Болгар чоры**
3) Алтын Урда чоры

3. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? Дөрес җавапны билгеләгез (2 балл):

*Йосыф әйтте: «Мине газиз сатып алды,*
*Минем гадәт-холкым аңа ошап калды,*
*Ул бит мине угълы итеп кабул кылды,* -
*Атама ничек хыянәт итим имди?*

*Хыянәтчеләрне Халикъ һич яратмый,*
*Дошманнарга җәзасыннан кире кайтмый,*
*Ярдәм сорап килгәннәрне кире какмый,*

*Сабыр ит син, курык, аңа сыен имди!».*

1) сабыр булырга кирәк
2) Хыянәтчеләрне Аллаһ яратмый
3) **үзеңә яхшылык кылганнарга хыянәт итәргә ярамый, Аллаһ андый кешене гафу итми, сабыр итеп яшәгәннәргә үзенең рәхмәтен һәм ярдәмен ирештерә**

4. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән алынган әлеге өзектә кайсы образлар символ булып килә? (2 балл):

*Туар кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз*
*Шул төшемдә сәҗдә кылды миңа төп-төз –*
*Бу төшемне шулай күрдем, һичбер шиксез,*
*Йә, әткәем, шул төшемне юра имди.*

Җавап: **<u>кояш, ай, йолдыз, төш</u>**

5. Кол Гали шәхесе белән бәйле төбәкләр урын алган рәтне күрсәтегез (1 балл):

1) **Кашан, Болгар, Хәрәзем**
2) Хәрәзем, Сарай, Мәскәү
3) Казан, Болгар, Хәрәзем

6. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре 1839 елда беренче тапкыр кайда басыла? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):

1) **Казан университеты типографиясе**
2) Татарстан китап нәшрияты
3) Кәримовлар матбагасы

7. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре кайсы жанрга карый? (2 балл):

Җавап: **<u>поэма / кыйсса</u>**

8. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән алынган әлеге өзектә кулланылган 2 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз (4 балл):

*Һәрбер әйткән сүзең туры, үзәк өзгеч,*
*Буең зифа, сының матур, гәүдәң төп-төз.*
*Бик зур байлык – аяк-куллар һәм нурлы йөз*
*Бүләк иткән күк иясе сиңа имди.*

*Кызыл якут кебек синең яңакларың,*
*Яшь алмадан нәфисрәктер иякләрең,*
*Бал-шикәрдән татлырактыр иреннәрең,* -
*Ике ирнең күңлем үртәп тора имди.*

Җавап: **<u>чагыштыру, эпитет һ.б.</u>**

9. Г.Тукайның «Кыйтга» шигырендә лирик геройга бәя бирегез. (5 балл)

*Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,*
*Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.*

*Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,*
*Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.*

*Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.*

10. Әлеге шигырьдә автор нинди фикерләр үткәрә? (6 балл)

**Лирик герой дөньяны үзгәртә, чистарта алмавы өчен сызлана. Дөньядагы кара көчләр кешене сындыра, каралта, шул яшәешне чистарта алмавы өчен кеше сызлана, ди автор һ.б.**

11. Г.Тукай иҗатына хас 3 сыйфатны, үзенчәлекне атагыз (6 балл).

## III. Иҗади бирем (10 балл).

«Тормыш ул – серле бер могҗиза...» юлларына нигезләнеп, 16 җөмләдән ким булмаган күләмдәге инша языгыз.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2023-2024 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 52 балл**

**I. Теоретик тестлар (10 балл).**

1. Әдәбиятның билгеле бер тарихи вакыт аралыгындагы хәрәкәте (1 балл):
1) **әдәби барыш (процесс)**
2) әдәбият тарихы
3) әдәбият белеме

2. Әдәби әсәрдә эмоциональ-мәгънәви көчкә ия кисәк, образның бер өлеше (1 балл):
1) лейтмотив
2) архетип
3) **деталь**

3. Гражданлык лирикасы үрнәкләре генә күрсәтелгән рәтне сайлап алыгыз (1 балл):
1) **«Кичер, илем!», «Иртә төшкән кар», «Җырларым»**
2) «Җырларым», «Тынма, давыл!»
3) «Тынма, давыл!», «Төрмәдә төш»

4. Күрсәтелгән образлар арасыннан кайсы әсәрдә символ вазифасын үти (1 балл):
1) Ә.Еникинең «Төнге тамчылар» әсәрендә портфель
2) Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт» әсәрендә бер саны
3) **Ф.Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә йөзек кашы**

5. Кечкенә күләмле, эмоциональлеге, ритмик төзелеше белән шигъри сөйләмгә якын булган һәм хис-кичерешләрнең үсеш-үзгәрешен күрсәтә торган чәчмә әсәр (1 балл):
1) **нәсер**
2) поэма
3) дастан

6. Эпик әсәрләр генә булган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) «Өч аршын җир», «Кыйссаи Йосыф», «Йөзек кашы»
2) «Беренче мәхәббәт», «Хөсрәү вә Ширин», «Йөзек кашы»
3) **«Төнге тамчылар», «Колыма хикәяләре», «Йөзек кашы»**

7. Билгеләмәне игътибар белән укыгыз һәм аңа туры килгән төшенчәне язып куегыз: «*Яшәешнең, кеше табигатенең асылын төгәл, дөрес итеп гәүдәләндерүче иҗат юнәлеше (тибы)*» (2 балл):

Җавап: **<u>реализм</u>**

8. Иҗат юнәлешләрен татар әдәбиятында формалаша бару тәртибендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны гына үсә бару тәртибендә языгыз (2 балл):

1) реализм
2) көнчыгыш романтизмы
3) модернизм

Җавап: **<u>213</u>**

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## II. Әдип иҗатына кагылышлы биремнәр (32 балл).

1. «Татарча язу танучы һәм бу дәфтәрне укучы дуска!

Моны татарның билгеле шагыйре … язды. Аның тарихы болай: ул 1906 елда туган. Квартиры Казанда һәм Мәскәүдә. Илдә иң зур шагыйрьләрдән санала. 1942 елны сугышка китте һәм әсир төште. Әсирлектә күп азаплар чигеп, кырык үлемнән калып, ахырында Берлинга китерелде. Берлинда сәяси яшерен оешмада катнашуда, совет пропагандасы таратуда гаепләнеп, кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлки, аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра…» Әлеге юлларның авторы кем? (2 балл):

Җавап: **<u>Муса Җәлил</u>**

2. Муса Җәлил әдәбиятның кайсы жанрларында эшли (1 балл):

1) либретто, лирик шигырь, повесть
2) лирик шигырь, нәсер, поэма
3) **лирик шигырь, поэма, либретто**

3. М.Җәлилнең «Кичер, илем!» шигыреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? Дөрес җавапны билгеләгез (2 балл):

*Тик бер өмит: кара август төне*
*Илтер мине шунда җитәкләп.*
*Өстен килер түбән әсирлеккә*
*Үч һәм илгә керсез мәхәббәт.*

*Тик бер өмит, дуслар: сезнең сафта*
*Табар соңгы көрәш теләген.*
*Яраланган, ләкин тар коллыкка*

*Баш имәгән керсез йөрәгем.*

1) шагыйрь йөрәге үлемсез
2) **әсир булганда да шагыйрь йөрәгендә илгә керсез мәхәббәт яши, шул мәхәббәт тар коллыкта да горур булып калырга көч бирә**
3) Туган илгә мәхәббәт – илаһи көч

4. М.Җәлилнең «Кичер, илем!» шигыреннән алынган әлеге өзектә лирик геройга бәя бирү өчен нинди символик образ кулланыла һәм ул нинди мәгънәдә килә? (2 балл):

*Чаян чага үзен соңгы чиктә,*
*Бөркет ярдан түбән ташлана.*
*Мин соң бөркет түгел идеммени,*
*Баш иярга шуннан башкага!*

*Ышан, илем, шундый бөркет идем*
*Мин дә, соңгы минут килгәндә.*
*Әзер идем мәгърур канат җәеп*
*Ташланырга ярдан түбәнгә.*

Җавап: **бөркет образы, лирик геройның кыюлыгын, батырлыгын, баш бирмәс рухын чагылдыра**

5. М.Җәлил шәхесе белән бәйле төбәкләр урын алган рәтне күрсәтегез (1 балл):
1) **Минзәлә, Казан, Мәскәү**
2) Волхов, Оренбург, Санкт-Петербург
3) Казан, Мәскәү, Арча

6. М.Җәлил әдәбиятның кайсы чорында актив иҗат эше белән шөгыльләнә? Дөрес җавапны билгеләгез (1 балл):
1) 1915-20 еллар
2) XX йөз башы
3) **Сугыш чоры**

7. М.Җәлилнең «Кичер, илем!» шигыре әдәбиятның кайсы төренә һәм аның нинди жанрына карый? (2 балл):

Җавап: **лирика / поэзия, гражданлык лирикасы**

8. М.Җәлилнең «Кичер, илем!» шигыреннән алынган әлеге өзектә кулланылган 2 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз (4 балл):

*Кичер мине, илем, синең бөек*
*Исмең белән килеп сугышка,*

*Данлы үлем белән кумалмадым*
*Бу тәнемне соңгы сулышта.*

*Юк, мин сине тузан бөртегедәй*
*Сансыз гомерем өчен өчен сатмадым.*
*Волхов шаһит: изге сугыш антын*
*Соң чиккәчә керсез сакладым...*

Җавап: **<u>риторик эндәш, инверсия, чагыштыру, метафора һ.б.</u>**

9. Муса Җәлилнең «Ялгыз учак» шигырендә лирик геройга бәя бирегез. (5 балл):

*Төн караңгы, учак яктым,*
*Тирә-ягым томан...*
*Мин диңгездә япа-ялгыз*
*Йөзгән кораб сыман.*

*Учагымның чаткылары*
*Томан ертып оча...*
*Чаткыларның яктылары*
*Киң бушлыкны коча.*

*Кызыл ялкын, телен сузып,*
*Уя җирнең битен.*
*Мин кайвакыт я сызгырып,*
*Яхут җырлап куям.*

*Томан аша ялтыраган*
*Утны күрмәсләрме?*
*Томан ертып ялтыраган*
*Җырга килмәсләрме?*

10. Әлеге шигырьдә автор нинди фикерләр үткәрә, учак образы нинди мәгънәләрдә кулланыла? (6 балл)

**Лирик герой үз иҗатының, шигъри сүзнең халык рухын уятачагына ышана. Учак образы шигъри сүз, иҗат, поэзия, шигъри күңел мәгънәләрендә кулланыла.**

11. Муса Җәлил иҗатына хас 3 сыйфатны, үзенчәлекне атагыз (6 балл).

**III. Иҗади бирем (10 балл).**

«Тел, Моң, Хәтер – рухның таяныч нигезе ул...» юлларына нигезләнеп, 18 җөмләдән ким булмаган күләмдәге инша языгыз.